# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘЛКИ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ КАРАРЫ

**2020 елның 5 июне** **308№**

Советның 2018 елның 17 декабрендәге «Әлки муниципаль районының вәкиллекле органы депутаты статусы турында»гы Нигезләмәне раслау хакында»гы 202 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131- ФЗ Федераль закон, 2008 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы тору турында»гы 273 - ФЗ номерлы Федераль закон, 2019 елның 16 декабрендәге «Коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнарын камилләштерү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында»гы 432 - ФЗ номерлы Федераль закон, 2020 елның 24 апрелендәге «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы 148-ФЗ номерлы Федераль закон һәм 2019 елның 26 июлендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законның 40 статьясына үзгәрешләр кертү хакында»гы 228-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Коррупциягә каршы тору турында»гы Федераль законның 13_1 статьясы нигезендә Әлки муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Әлки муниципаль районы вәкиллекле органы депутаты статусы турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

-4 пунктка түбәндәге эчтәлекле 3 абзац өстәргә:

«Әлки муниципаль районының вәкиллекле органы депутатына үз вәкаләтләрен тотрыксыз рәвештә гамәлгә ашыру өчен Россия Федерациясе субъекты законы нигезендә Әлки муниципаль районы Уставы белән билгеләнә торган чорга эш урынын (вазыйфасын) саклау гарантияләнә һәм ул аена ике көннән ким һәм алты эш көненнән дә артык булмаска тиеш.»

15 статьясына:

-2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутат, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты хокуклы түгел:

1) эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шәхсән яки ышанычлы затлар аша шөгыльләнергә;

2) түбәндәге очраклардан тыш, коммерция яки коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга:

а) түләүсез нигездә сәяси партия, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органы, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты белән идарә итүдә, съездда (конференциядә), яисә башка иҗтимагый оешманың, торак, торак төзелеше, гараж кооперативларының, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтләренең гомуми җыелышында катнашу;

б) түләүсез нигездә коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә (сәяси партия, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органы, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты белән идарә итүдән, съездда (конференциядә), яисә башка иҗтимагый оешманың, торак, торак төзелеше, гараж кооперативларының, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтләренең гомуми җыелышыннан тыш) Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнгән тәртиптә, Россия Федерациясе субъектының югары вазыйфаи затына (Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесе) алдан хәбәр итеп катнашу;

в) түләүсез нигездә Россия Федерациясе субъекты муниципаль берәмлекләре советында, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен тәкъдим итү;

г) түләүсез нигездә гамәлгә куючы (акционер, анда катнашучы) муниципаль берәмлек булган оешманың идарә һәм ревизия комиссиясе органнарында, муниципаль берәмлек исеменнән оешманы гамәлгә куючы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар яки муниципаль милектә булган акцияләр (устав капиталында өлешләр) белән идарә итү тәртибе нигезендә муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен тәкъдим итү;

д) федераль законнарда каралган башка очраклар;

3) мөгаллимлек, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлектән тыш, башка түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнергә. Шул ук вакытта укытучылык, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлек, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе яисә Россия Федерациясе законнары белән башкасы каралмаган булса, чит ил дәүләтләре, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар акчалары хисабына финанслана алмый;

4) Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, идарә органнары, попечительләр яки күзәтү советлары, коммерциягә карамаган чит ил

хөкүмәтнеке булмаган оешмаларның башка органнары Россия Федерациясе территориясендә гамәлдә булган структур бүлекчәләрнең составына керергә.»

- 2.2 пунктта «җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты» сүзләреннән соң «күрсәтелгән затларга карата башка төр җаваплылык чараларын куллану» сүзләрен өстәргә;

- 2 пунктның 5 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Депутат, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты 2008 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы тору турында»гы 273-ФЗ номерлы Федераль законда һәм башка федераль законнарда билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, бурычларны үтәргә тиеш.javascript:; Депутат, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләре 2008 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы тору турында»гы 273-ФЗ номерлы Федераль законда, 2012 елның 3 декабрендәге «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында»гы 230-ФЗ номерлы Федераль законда, 2013 елның 7 маендагы «Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм аларга ия булу, кулдагы акча һәм кыйммәтләрне саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында»гы 79-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, бурычларны үтәмәгән очракта, әгәр федераль законда башкасы каралмаган булса, вакытыннан алда туктатыла.»

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында»гы http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырып чыгарырга, Әлки муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

**Совет Рәисе,**
**Әлки муниципаль район Башлыгы:** **А. Ф. Никошин**

Совет Алькеевского муниципального района РТ